**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

# КАРАР

«11» 11 2025 ел Яр Чаллы ш. №3727

ТР Тукай муниципаль районы «Мәләкәс урта белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләргә тарифны раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Тукай муниципаль районы» муниципаль берәмлеге уставының 29 статьясы 20 пункты, «Муниципаль мәгариф оешмалары хезмәтләренә тарифларны исәпләү тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында» ТР Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының 2017 елның 10 гыйнварендәге 4 номерлы карары нигезендә

**КАРАР БИРӘ:**

1. ТР Тукай муниципаль районы «Мәләкәс урта белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе тарафыннан күрсәтелә торган түләүле хезмәт бәяләре прейскурантына кертелгән хезмәтләр бәясе хисабын 1 кушымта нигезендә расларга.
2. ТР Тукай муниципаль районы «Мәләкәс урта белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе тарафыннан күрсәтелә торган түләүле хезмәт бәяләре прейскурантына кертелгән хезмәтләр бәясе хисабын 2 кушымта нигезендә расларга.
3. Карарның гамәлдә булуы 2025 елның 01 октябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.
4. Әлеге карарны ТР Тукай муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында урнаштырырга.
5. Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының 2024 елның 19 ноябрендәге 5187 номерлы, 2025 елның 17 февралендәге 280 номерлы карарларын үз көчләрен югалткан дип танырга.
6. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны «ТР Тукай муниципаль районы мәгариф идарәсе» муниципаль казна учреждениесе башлыгы вазыйфаларын башкаручы Э.Р. Низамиевага йөкләргә.

Башкарма комитет Җитәкчесе Л.Н. Маняпов

Муниципаль район Башкарма комитетының 2025 елның «11» 11 3727 номерлы карарына 1 кушымта

2025 елның 1 октябреннән Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы «Мәләкәс урта гомуми белем бирү мәктәбе» МБГББУ буенча түләүле хезмәтләр күрсәтүгә бер тәрбияләнүчегә бәяләр прейскуранты

| № | Хезмәтнең исеме | Хезмәт бәясе (сум) | Хезмәт күрсәтү дәвамлылыгы |
|---|---|---|---|
| 1 | «Дошколенок» | 600,00 | Айга 1 тапкыр (4 дәрес) |
| 2 | «Теориядән практикага» | 500,00 | Айга 1 тапкыр (4 дәрес) |
| 3 | «Туган тел, минем белән дус!» | 500,00 | Айга 1 тапкыр (4 дәрес) |
| 4 | «Акыллы малайлар һәм кызлар» | 500,00 | Айга 1 тапкыр (4 дәрес) |
| 5 | «Пифагор» | 500,00 | Айга 1 тапкыр (4 дәрес) |
| 6 | «Математика сорауларда һәм җавапларда» 1 төркем | 500,00 | Айга 1 тапкыр (4 дәрес) |
| 7 | «Математика сорауларда һәм җавапларда» 2 төркем | 500,00 | Айга 1 тапкыр (4 дәрес) |
| 8 | «Палитра» | 500,00 | Айга 1 тапкыр (4 дәрес) |
| 9 | «Умка» | 500,00 | Айга 1 тапкыр (4 дәрес) |
| 10 | «Белем калейдоскопы» | 500,00 | Айга 1 тапкыр (4 дәрес) |
| 11 | «Funny English Club» | 500,00 | Айга 1 тапкыр (4 дәрес) |

2026 елның 1 январеннан

| № | Хезмәтнең исеме | Хезмәт бәясе (сум) | Хезмәт күрсәтү дәвамлылыгы |
|---|---|---|---|
| 1 | «Дошколенок» | 650,00 | Айга 1 тапкыр (4 дәрес) |
| 2 | «Теориядән практикага» | 550,00 | Айга 1 тапкыр (4 дәрес) |
| 3 | «Туган тел, минем белән дус!» | 550,00 | Айга 1 тапкыр (4 дәрес) |
| 4 | «Акыллы малайлар һәм кызлар» | 550,00 | Айга 1 тапкыр (4 дәрес) |
| 5 | «Пифагор» | 550,00 | Айга 1 тапкыр (4 дәрес) |
| 6 | «Математика сорауларда һәм җавапларда» 1 төркем | 550,00 | Айга 1 тапкыр (4 дәрес) |

ТР Тукай муниципаль районы «Мәләкәс урта гомуми белем бирү мәктәбе» МБГББУ тарафыннан түләүле хезмәтләр күрсәтүгә бәяләр прейскурантына кушымта

1. **«Дошколенок»** - мәктәпкәчә яшьтәге балаларны яңа белем бирү шартларына уңышлы яраклаштыруга һәм бер белем бирү баскычыннан икенчесенә гуманлы (уңайлы) күчү шартларын булдыруга юнәлдерелгән.

Әлеге хезмәт 6 яшьтән алып 7 яшькә кадәрге балаларга, кабинетның мәйданы 46,9 кв.м., балалар саны - 7.

2. **«Теориядән практикага»** - 2025 елда кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып, рус теленнән имтиханга әзерләнүгә юнәлтелгән. Шуңа бәйле рәвештә программада рус теле буенча дәүләт йомгаклау аттестациясенә әзерлек бурычларына туры китереп сайлап алынган фонетика, морика, морфемика һәм сүз төзелеше, морфология һәм орфография, синтаксис һәм пунктуация, рус теле стилистикасы өлкәсеннән төшенчәләр системасын; укучыларны төп дәүләт имтиханының 3 өлешен үтәүгә әзерләү буенча сөйләм белеме төшенчәләре системасын; рус әдәби теленең төп нормалары турында мәгълүматны үз эченә ала.

Әлеге хезмәт 14 яшьтән 15 яшькә кадәрге балаларга бирелә, кабинетның мәйданы 40,8 кв.м., балалар саны - 20.

3. **«Туган тел, минем белән дус!»** - укучылар алган теоретик белешмәләрне киңәйтә һәм системага сала, практик күнекмәләрне ныгыта, бушлыкларны белемнәрдә тулыландырырга мөмкинлек бирә, укучыларны контроль эшләрне уңышлы язуга әзерләүне максат итеп куя.

Әлеге хезмәт 13 яшьтән 14 яшькә кадәрге балаларга бирелә, кабинетның мәйданы 40,8 кв.м., балалар саны - 15.

4. **«Акыллы малайлар һәм акыллы кызлар»** - логик фикерләүне үстерүгә, кече мәктәп укучыларын төп фикерләү операцияләре күнекмәләренә өйрәтүгә юнәлтелгән: чагыштыру, классификацияләү, билгеләмәләр бирү, нәтиҗәләр төзү, закончалыкларны аерып чыгару, фикер йөртү һ.б.

Әлеге хезмәт 8 яшьтән 9 яшькә кадәрге балаларга бирелә, кабинетның мәйданы 45,1 кв.м., балалар саны - 12.

5. **«Пифагор»** - укучыларның гомуми интеллектуаль үсешенә юнәлтелгән, табигый фән юнәлешенә ия. Әлеге программаның аермалы үзенчәлеге шунда, ул кыенлыклары математик эчтәлек белән генә түгел, математик ситуациянең яңа һәм гадәти булмаган булуы белән билгеләнә торган бурычлар һәм биремнәрне кертүне күздә тота, бу укучыларда үрнәктән баш тартырга, мөстәкыйльлек күрсәтергә, шулай ук зирәклекне, кызыксынучанлыкны эзләү һәм үстерү шартларында эшли белүләрен формалаштырырга ярдәм итә.

Әлеге хезмәт 12 яшьтән 14 яшькә кадәрге балаларга бирелә, кабинетның мәйданы 46,8 кв.м., балалар саны - 17.

| | | | |
|---|---|---|---|
| 7 | «Математика сорауларда һәм җавапларда» 2 төркем | 550,00 | Айга 1 тапкыр (4 дәрес) |
| 8 | «Палитра» | 550,00 | Айга 1 тапкыр (4 дәрес) |
| 9 | «Умка» | 550,00 | Айга 1 тапкыр (4 дәрес) |
| 10 | «Белем калейдоскопы» | 550,00 | Айга 1 тапкыр (4 дәрес) |
| 11 | «Funny English Club» | 550,00 | Айга 1 тапкыр (4 дәрес) |

ТР Тукай муниципаль районы
«Мәләкәс урта гомуми белем бирү
мәктәбе» МБГББУ директоры _______________ И.Н. Кузнецова

«Бюджет һәм казна учреждениеләренә хезмәт
күрсәтү үзәге» МБУ җитәкчесе урынбасары _______________ Р.Р. Йосыпова

6. **«Математика сорауларда һәм җавапларда»** - теоретик материалның минималь киңәюендә катлаулы бурычларны, тарихи белешмәләрне, мавыктыргыч характердагы материалларны кертү аша төп курска тоташкан һәм аны тирәнәйтә торган аерым мәсьәләләрне өйрәнүгә юнәлтелгән.

Әлеге хезмәт 13 яшьтән 15 яшькә кадәрге балаларга бирелә, кабинетның мәйданы 46,8 кв.м., балалар саны:

- 1 төркем 15 кеше;
- 2 төркем 20 кеше.

7. **«Палитра»** - балаларның иҗади потенциалын, төрле сәләтләрен үстерүгә юнәлтелгән. Программаның эчтәлеге үз иҗаты һәм үткән тәҗрибәне үзләштерү аша иҗади шәхес культурасын формалаштыруга юнәлтелгән. Программаның эчтәлеге балаларның рәсем сәнгате төрләре, жанрлары турында күзаллауларын киңәйтә, традицион булмаган техникалар белән таныштыра, гармония һәм эстетик зәвык хисе формалаштыра, кешеләрнең тормышында сәнгатьнең билгеләнешен аңларга өйрәтә, балаларда сәнгать күзаллауларын формалаштыра һәм танып белү кызыксынуын үстерә. Төрле тематика ярдәмендә балалар әйләнә-тирә дөньяны танып беләләр, анда матурлыкны күрергә өйрәнәләр, күргәннәрен үз тәҗрибәләре, хисләре һәм күзаллаулары белән бәйлиләр. Иң мөһиме - балаларны иҗат процессына җәлеп итү.

Әлеге хезмәт 7 яшьтән 10 яшькә кадәрге балаларга бирелә, кабинетның мәйданы 28,5 кв.м., балалар саны - 12.

8. **«Умка»** - танып-белү сәләтләрен һәм гомумбелем бирү күнекмәләрен үстерүгә юнәлтелгән.

Әлеге хезмәт 7 яшьтән 8 яшькә кадәрге балаларга бирелә, кабинетның мәйданы 47,8 кв.м., балалар саны - 23.

9. **«Белем калейдоскопы»** - укучыларның математика, рус теле, әйләнә-тирә дөнья буенча белемнәрен тирәнәйтүгә һәм киңәйтүгә; башлангыч мәктәпне тәмамлаучыларың бөтенроссия тикшерү эшенә әзерлеген арттыру өчен шарлар тудыруга юнәлтелгән.

Әлеге хезмәт 9 яшьтән 11 яшькә кадәрге балаларга бирелә, кабинетның мәйданы 46,9 кв.м., балалар саны - 19.

10. **«Funny English Club»** - баланы башлангыч мәктәптә уңышлы укытуга әзерләүгә, яңа белем бирү этабына уңайлы күчүне тәэмин итүгә һәм уен дәресләре, җырлар һәм проектлар аша инглиз теленә кызыксыну уятуга юнәлтелгән.

Әлеге хезмәт 7 яшьтән 8 яшькә кадәрге балаларга бирелә, кабинетның мәйданы 43,7 кв.м., балалар саны - 11.

ТР Тукай муниципаль районы
«Мәләкәс урта гомуми белем бирү мәктәбе» МБГББУ директоры _______________ И.Н. Кузнецова